Татарстан Республикасы
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы

# БОЕРЫК

2015 елның 12 марты Казан ш. № 36/2-пр

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2015 елга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 2015 елның 15 гыйнварындагы 3/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Үсемлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә бәйләнешсез ярдәм күрсәтү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 2012 елның 27 декабрендәге 1431 номерлы карарын үтәү өчен һәм авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр күләмен арттыру максатларында

боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2015 елга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 2015 елның 15 гыйнварындагы 3/2-пр номерлы боерыгына (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Боерыкка 1 нче кушымтаның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр өчен 1 гектар чәчү мәйданына субсидияләр күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$V = П \times (136{,}0 + (2{,}25 \times У) + (49{,}0 \times Иппмр))$,

монда:

V – күчерелә торган субсидияләрнең күләме, сум;

П – гектарларда исәпләнгән чәчү мәйданы, ул факттагы чәчүлекләр мәйданнары турындагы мәгълүмат белән дәлилләнә, мәгълүмат нигезендә исә 2014 ел уңышын җыеп алу турында рәсми статистик хисап төзелә (алга таба – уңыш җыеп алу турында мәгълүмат);

136,0 – бер гектар чәчүлек мәйданына минималь ставка, сум;

2,25 – ашлык берәмлекләрен җитештерүнең 1 центнерына ставка, сум;

У – авыл хуҗалыгы культураларының уртача уңдырышлылыгы, ул Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының “Авыл хуҗалыгы культураларын ашлык берәмлекләренә күчерү коэффициентларын раслау турында” 2013 елның 11 гыйнварындагы 6 номерлы боерыгына ярашлы рәвештә 2014 елга уңыш җыеп алу турында мәгълүматка нигезләнеп бер гектар чәчүлектән алынган ашлык берәмлекләренең центнерларында күрсәтелә.

49,0 – чәчүлекнең бер гектарына җирләрнең уңдырышлылыгы буенча уртача ставка, сум;

Ипп.мр – Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча туфрак уңдырышлылыгының уртача алынган индексы, ул әлеге тәртипкә кушымта нигезендә “Татарский” агрохимия хезмәте үзәге” федераль дәүләт бюджет учреждениесе һәм “Әлмәт” агрохимия станциясе” федераль дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – агрохимия хезмәтләре) тарафыннан тапшырылган мәгълүматларга нигезләнеп Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының “Россия Федерациясе субъектында туфрак уңдырышлылыгы күрсәткечләрен исәпләү методикасын раслау турында” 2013 елның 11 гыйнварындагы 5 номерлы боерыгы белән расланган методика нигезендә билгеләнә.”.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасарлары Н.Л. Титовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов